БӘРӘКӘТЛЕ ҮЛӘН

Акча аяк астында, иелеп алырга гына кирәк

> 2

ТУЙГАНЧЫ ЙОКЛЫЙЛАР

Мәктәп укучыларының язгы каникулы башланды

> 2



УКРАИНАДА НИШЛИБЕЗ?

Махсус хәрби операция турында 10 сорауга җавап

> 3

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ГАГАРИН

Беренче космонавт янәшәсендә татарлар күп була

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 43 (28816) | Сишәмбе | 29 март | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru

/vatanimtatarstan

4604609 000131

Вазгыять

Соңгы арада ил халкы күпләп тотылган көнкүреш техникасы сатып ала башлаган. «РИА Новости» агентлыгы иң популяр бушлай белдерү сайтларын анализлаганнан соң шундый нәтиҗәгә килгән. Март аенда тотылган көнкүреш техникасына сорау 16–35 процентка арткан. Сәбәбе барыбызга да билгеле. Бар нәрсәгә бәя котырып үскән көннәрдә көнкүреш техникасы да ике-өч мәртәбә кыйммәтләнде. Өстәвенә соңгы арада күпләр кибет киштәсендә кирәкле техниканы табып булмый дип зарлана.

«Татар-информ»

ИСКЕСЕ ДӘ ЯРЫЙ

ТОТЫЛГАН КӨНКҮРЕШ ТЕХНИКАСЫ АЛУЧЫЛАР САНЫ АРТКАН

Көнкүреш техникасына бәяләр ел башында кыйммәтләнә башлаган иде инде. Ник дигәндә, күпләр, акча алышыначак икән дигән имеш-мимешләргә ышанып, шул рәвешле җыелган акчасын саклап калырга тырышты. AliExpress порталы хезмәткәрләре белдерүенчә, гыйнвар аенда кайбер төр техникага сорау, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 4–5 тапкыр арткан. Аерым алганда, агымдагы елның беренче аенда эре көнкүреш техникасы – 3,4 тапкыр, вак техника – 1,4 тапкыр, смартфоннар 1,6 тапкыр күбрәк сатылган.

Соңгы арада килеп туган вазгыять хәлне тагын да катлауландырды. Россиягә каршы кертелгән чикләүләр аркасында электрон һәм көнкүреш җиһазлары җитештерүче LG, Samsung, Dell, Sharp, Apple, Nokia кебек эре оешмалар безнең илдә эшчәнлеген туктатты. 1 марттан Россиядә Apple техникасының да сатылмаячагы билгеле булды. Бу исә көнкүреш техникасына, смартфоннарга бәяләрне бермә-бер арттырды. Әйтик, соңгы бер ай эчендә кибетләрдә электрон җиһазлар – 13 процентка, телефоннар 10 процентка кыйммәтләнгән. Өстәвенә бүген кибет киштәләрендә кайбер төр көнкүреш техникасына кытлык та күзәтелә.

«Юла» һәм «ВКонтакте» челтәрендәге белдерүләр сервисы мәгълүматларына караганда, 1–21 март аралыгында биредә смартфон һәм көнкүреш техникасына ихтыяҗ, февраль аеның шул ук чоры белән чагыштырганда, 35 процентка арткан. Бүген халык биредә күбрәк тотылган телефон яки планшет (51 процент) сатып ала икән. Көнкүреш техникасы (20 процент) белән компьютерны (12 процент) кулдан гына сатып алырга теләүчеләр дә шактый.

Бушлай белдерүләр сайтында күрсәтелгән бер номер буенча без дә элемтәгә чыктык. Чаллыда яшәүче Артем исемле егет 20 мең сумга кадәр ноутбук алырга тели. «Эш өчен кирәк. Ватылган ноутбугымның яңасы кибетләрдә 36 мең сум тора. Шуңа кулдан гына алып торырга булдым», – ди ул. Иттарткыч сатып алу турындагы игълан буенча шалтыраткач, телефонны алган ир-ат фәлән маркадагы иттарткычны бер детале өчен генә сатып алырга теләвен әйтте.

Белгечләр тотылган көнкүреш кирәк-ярагы сатып алучылар саны арту белән мошенниклык очраклары да күбәячәк дип фаразлый. Бушлай белдерүләр сайты аша әйбер сатып алучыларга бу куркыныч аеруча яный. IT-куркынычсызлык буенча белгеч Максим Ибатуллин, кырыгалдарлар тозагына эләкмәс өчен, инде барыбыз да ятлап диярлек өлгергән гади генә кагыйдәләрне истә тотарга өнди. «Кулдан әйбер сатып алганда, товар бәясенең бер өлешен алдан түләп куюны сорасалар, ризалашмагыз. Кешене еш кына әнә шул рәвешле төп башына утырталар да инде. Чит-ят номердан килгән шикле ссылкалар буенча кереп карап та акчагыздан колак кагарга мөмкин. Үзегез турындагы шәхси мәгълүматны, банк картасының арткы ягындагы өч санны (CVV/CVC-код), смс-хәбәрдә килгән кодны беркемгә дә әйтмәгез», – ди белгеч.

Кесә ягы такырайган көннәрдә, күп кенә кибетләрдә көнкүреш техникасын кредитка яки өлешләп түләү шарты белән алып булмавы да ачыкланды. Юкса күп әйберне кредитка, рассрочкага алырга гадәтләнгән идек инде. Хәзер аларына да өмет юк. Бу хәбәрне «ВТ» хәбәрчесе элемтәгә кергән «DNS», «М.Видео» кибетләрендә дә расладылар.

Аналитик Эльдар Мортазин фикеренчә, кредит белән рассрочка дигәнең көнкүреш техникасы сатучы кибетләргә тиз генә әйләнеп кайтмас әле. Моның өчен берничә ел ук таләп ителергә мөмкин дип фаразлый ул. «Рассрочканы икенче төрле яшерен ташлама дип тә әйтеп була. Әмма хәзерге вазгыятьтә андый ташлама ясау отышлы түгел. Бу көнкүреш техникасына бәя артуга китерәчәк. Күмәртәләп сату өчен кредит та отышлы түгел. Ник дигәндә, банктан акча торкарлык белән килә. Сумның торыксызлыгы аркасында, тиешле акча килеп җиткәндә, кеше алырга җыенган техниканың бәясе тагын да арткан булырга мөмкин. Кредит, рассрочка алу мөмкинлеге яңартылган очракта, болай да кыйммәт техниканы ике санлы процент ставкасы белән бурычка алучы булмаячак, билгеле», – ди белгеч.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КӨНКҮРЕШ ТЕХНИКАСЫН КУЛДАН САТЫП АЛЫРГА ҖЫЕНГАН КЕШЕГӘ КИҢӘШЛӘР

➤Иске җиһаз сатып алудан мәгънә юк. Әйтик, кер юу машинасы беренче тапкыр ватылганчы, кагыйдә буларак, 3–5 ел эшли. Суыткыч исә 8–10 елдан ватыла. Шуңа күрә 6–7 еллык кер юу машинасы сатылу турында белдерүне читләтеп үтүең хәерле.

➤Тотылган җиһазларны комиссион кибетләрдә дә сатып алырга мөмкин. Әмма ул анда бераз кыйммәтрәк тора. Ләкин бушлай белдерү сайтлары аша әйбер сатып алу белән чагыштырганда, монда сез үзегезгә кирәкле әйберне тотып, тикшереп карый аласыз.

➤Кибетләрдәге тотылган көнкүреш техникасы бүлекләрендә дә шактый акчаны янга калдырырга мөмкин. Билгеле булганча, биредә күчергәндә, төшергәндә кителгән, яньчелгән техника сатыла. Алар, зыянның зурлыгына карап, 5–30 процентка арзанрак тора. Шул рәвешле биредә сату бәясеннән өч тапкыр арзанрак хакка бераз яньчелгән, әмма өр-яңа суыткыч алып була.

Без – бишенче

Татарстан узган елда социаль-икътисади үсеш буенча иң яхшы 10 төбәк исемлегендә бишенче урынга чыккан. Росстат, Финанс министрлыгы, Салым һәм Казначылык хезмәтләре мәгълүматлары нигезендә төзелгән рейтинг нәтиҗәләре шундый. Ямал-Ненец автономияле округы, Мәскәүне узып, беренче урынны алган. Ханты-Манси автономияле округы – өченче. Иң яхшы дистә төбәккә шулай ук Санкт-Петербург, Татарстаннан соң – Коми һәм Чиләбе өлкәләре (алтынчы урынны бүлешкәннәр), Мәскәү өлкәсе, Пермь, Красноярск крайлары (сигезенче), Кемерово, Свердловск һәм Иркутск өлкәләре (унынчы) кергән.

Рейтингта төбәктәге уртача хезмәт хакы, яшәү минимумы, сәнәгатьтә җитештерү күләме, төбәк бурычының бюджет кеременә карата нисбәте исәпкә алынган.

1 апрельдән үзгәрә

Президент Владимир Путин Хөкүмәткә 1 апрельдән ташламалы ипотека шартларын үзгәртергә кушкан. Белүебезчә, процент ставкасы үсеп, 12 процентка җиткерелә, шул ук вакытта кредитның чик күләме дә арта. Ташламалы ипотека яңа төзелгән йортлардагы фатирларны сатып алу өчен бирелә. Хәзер кредитның иң зур күләме Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре, Мәскәү һәм Ленинград өлкәләрендә яшәүчеләр өчен – 12 миллион сум, башка төбәкләр өчен 6 миллион сумга кадәр булачак.

Шул ук вакытта авыл, гаилә, Ерак Көнчыгыш ипотекалары буенча ставкалар сакланып кала. Сүз уңаеннан, Президент Хөкүмәт әгъзалары белән киңәшмә барышында билгеләп үткәнчә, ташламалы ипотека 12 процентка җиткерелсә дә, чынбарлыкта булырга тиешле саннан ике тапкыр диярлек кимрәк.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңа һөнәргә өйрәтәләр

Россиядә яңа һөнәргә бушлай өйрәтү программасы башланды. Эштән җибәрелү куркынычы янаган кешеләр анда катнашуга заявка тапшыра ала. Хәзер пенсия алды яшендәгеләр, 50 яшьтән өлкәнрәкләр, бала карау ялындагы аналар, мәктәпкәчә яшьтәге сабыйлары булган эшсез хатын-кызлар бушлай курсларга язылырга мөмкин. Илнең Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы хәбәр иткәнчә, барлыгы 23 меңнән артыграк мәгариф программасы булдырылган. Һәр төбәк, үзенең хезмәт базары ихтыяҗыннан чыгып, теге яки бу программаны сайлап ала.

Яңа һөнәргә өйрәтүгә заявкалар «Работа в России» порталында кабул ителә. Программа «Демография» илкүләм проекты кысасында гамәлгә ашырыла. Хезмәт һәм социаль яклау министры Антон Котяков билгеләп үткәнчә, узган елда яңа һөнәргә өйрәтелүчеләрнең 75 проценты эшкә урнашкан. Быел 345 меңгә якын кеше яңа белемнәр үзләштерәчәк.

Битараф калмаганнар

Донецк һәм Луганск Халык Республикаларына Татарстан районнары да булыша. Бу көннәрдә республиканың Тәтеш, Актаныш, Алексеевск районнары әлеге өлкәләрдә яшәүчеләргә 55 тонна гуманитар ярдәм җыеп тапшырды.

Ярдәмнең зур өлеше Тәтеш районына карый. Район башлыгы Рәмис Сафиулловның шәхси иганә ярдәме белән, 40 тонна азык-төлек җыелган. Кирәк-яраклар арасында ярмалар, он, шикәр комы, үсемлек мае, чәй, тәм-томнар да бар. Барлыгы 2 меңләп тартма әзерләгәннәр.

Актаныш районыннан 10 тонна он, 10 азык-төлек тартмасы (эчендә ярма, үсемлек мае, тушенка, каһвә, чәй, шикәр комы һәм башка кирәк-яраклар) әзерләп тапшырганнар. Ярдәмне битараф булмаган шәхси эшкуарлар күрсәткән.

Алексеевск районыннан шулай ук он, шикәр комы, тоз, ит ризыкларыннан торган 3 тонна азык-төлек продукциясе җыйганнар. Матди ярдәм күрсәтүчеләр арасында районның шәхси эшкуарлары, коммерция оешмалары һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре бар.

Җыелган продукцияне илтеп тапшыру өчен Россия Оборона министрлыгының ике Ил-76 очкычын файдаланганнар. Гуманитар ярдәмне Донецк Халык Республикасына кадәр Тәтеш районы башлыгы Рәмис Сафиуллов озата барган.

COVID-19

Ашаганда гына саласы

Татарстанда коронавируска каршы кертелгән чикләү чаралары бер-бер артлы гамәлдән чыга башлады. Хәзер республика халкы нинди кагыйдәләр буенча яши?

Билгеле булганча, 21 февральдән Татарстанда QR-код куллану системасы бетерелде. Театр-кинога керү, җәмәгать транспортында йөрү, кафе-ресторанга бару өчен кара шакмаклар кирәк түгел хәзер.

Шулай ук 21 февральдән республикада кибетләрнең төнге эшчәнлегенә карата тыюны алдылар. Сауна һәм мунчалар да төнге сәгатьләрдә хезмәт күрсәтә ала.

21 февральдән яшүсмерләр янә сәүдә-күңел ачу комплексларына әти-әниләре яки законлы вәкилләреннән башка гына йөрү мөмкинлеген алды.

Узган атна ахыры исә кафе-ресторан тотучыларга күңелле яңалык алып килде. Татарстанда җәмәгать туклануы урыннарына төнге сәгатьләрдә эшләргә рөхсәт ителде. Тиешле карарны республика Премьер-министры Алексей Песошин имзалады.

Искәртеп үтик: 2021 елның 30 октябреннән башлап кафе-рестраннарга 23.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр хезмәт күрсәтү тыелган иде. Хакимият вәкилләре моны коронавирус инфекциясе йоктыручыларның кискен артуы белән аңлатты. Чикләү турында Яңа ел бәйрәме вакытында гына онытып тордылар: 31 декабрьдән 1 гыйнварга каршы төндә кафе-рестораннар 03.00 сәгатькә кадәр эшләде.

kzn.ru

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсендә бу адымга китергән сәбәпләр турында менә нәрсә диделәр:

– 2022 елның сигезенче атнасыннан коронавирус белән чирләүчеләрнең атна саен уртача алганда 30 процентка кимүен күзәттек. Инфекция таралу коэффициенты – 0,7 процент. Республикада коронавируска каршы вакцина ясатучылар күрсәткече 81,7 процентны тәшкил итә. 60 яшьтән өлкәнрәкләрнең 76,6 проценты прививка кадатты. Грипп белән чирләү очраклары да бу елның алтынчы атнасыннан башлап теркәлми. Кискен респиратор вируслы инфекцияләр белән авыру эпидемиологик чиктән 50 процентка кимрәк.

Моңа да карамастан, Татарстанда әле дә битлек кию режимы саклана. Аны җәмәгать урыннарында, транспортта да кияргә кирәк. Сәламәтлек турында сөйләгәндә гигиенага бәйле иң гади кагыйдәләрне дә онытмыйсы.

САН

Узган тәүлектә Татарстанда коронавирус йоктырган 279 кеше теркәлгән, 51е – балалар. 50 кеше хастаханәдә дәвалана. Вакцина ясатучылар санына килгәндә, республикада аларның саны – 2497036. Кабат вакцинация узучылар – 278727 кеше.

Сүзгә-сүз

Виктория АБРАМЧЕНКО, РФ Премьер-министры урынбасары:

Икмәк бәяләре тотрыклы булсын өчен, хөкүмәт федераль бюджеттан 2,5 млрд сум бүлеп бирде, акча төбәкләргә җибәрелде инде. Федераль һәм төбәк субсидияләре ярдәмендә җитештерүчеләр 2022 елның март башында яки уртасында булган бәяләрне калдырып, аны ел ахырына кадәр күтәрми тора алачак.

(Вице-премьерның матбугат хезмәте хәбәре)

ТАТАРСТАНДА – ТОРАК ТӨЗЕЛЕШЕ

Республикада быел 797 мең кв. метр торак төзелгән. Бу – еллык планның 29 проценты.

ШӘХСИ ЙОРТЛАР – 4243 йорт – 34%

СОЦИАЛЬ ИПОТЕКА – 73 мең кв. метр – 49%

КОММЕРЦИЯЛЕ ТӨЗЕЛЕШ – 151 мең кв. метр – 16%

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

ВАКЫЙГАЛАР АГЫШЫ ТИЗЛӘНГӘНДӘ

Үткән атнада геосәяси вазгыять динамикасы артты. Атна азагы җәнҗаллы белдерүләр, зур сугышка әверелү ихтималы булган конфликтлар учагын дөрләтергә тырышулар, вакыйгаларның тизләнүе белән истәлекле булды.

Европада берьюлы диярлек берничә саммит узды. Америка лидеры Джо Байден катнашында европалы җитәкчеләр Россиягә каршы бердәм хәрәкәтләр планын төзергә тырышты. Зур сөйләшүләрдән соң, Байден Польшага килде. Украина чигеннән 80 километр гына ераклыкта урнашкан Жешув шәһәрендәге америкалы гаскәриләр белән сөйләште, бер табынга утырып ашады. Америка президентының Польшага визиты зур сенсация белән төгәлләнергә тиеш дип көтелде. Бигрәк тә аның Варшавада шимбә кичендә ясаячак нотыгы зур сәяси шартлау ясар, дигән хәбәрләр таратылды. Варшава нотыгында зур яңалыклар ишетелмәде ләкин. Украина ягыннан торып НАТО конфликтка катнашмаячак, әмма Мәскәүгә санкцияләр басымы дәвам итәчәк, Киевка корал белән ярдәм итү туктамаячак. Ләкин Жешувтагы базада солдатлар белән сөйләшкәндә, хәтерсез Байден сенсация булырлык бер фраза ычкындырды ычкындыруын. «Украиннарның батырлыгын үз күзләре белән күрү һәм бәяләү анда (ягъни Украинага. – **Р.Ф.**) баргач мөмкин булачак», – дигән сүзләр әйтте. «Российская газета» моны Байден АКШның киләчәктә Украинага үз гаскәрләрен кертү планын сатты дип бәяләде. Моннан тыш Польшада Путинны хакимияттән читләштерү нияте булып аңлашыла торган сүзләр дә яңгырады. Хәзер Вашингтон дипломатиясе Байден сүзләрен «чистартып», аның белдерүләрен йомшартып азаплана, Россиягә каршы да, аның Президентына каршы да агрессив ниятләр юклыгына ышандырырга тырыша. Байден үзе дә сүзләреннән баш тарта.

Россиянең көнбатыш чикләрендә генә түгел, планетаның башка почмакларында да хәрби конфликтлар шытарга азаплана. Азәрбайҗан Таулы Карабах төбәгендә яңадан «Байрактар»лар кулланды. Баку үзен бик дорфа тота. Бу уңайдан Иран ягыннан көтелмәгән белдерү яңгырады. Тәһран үз гвардиясенең (Ислам революциясен саклаучылар корпусы) Ереванны яклаячагын белдерде. Конфликт үсеп китә калса, Иран – Азәрбайҗан – Төркия» катнашындагы зур бәрелешкә әверелү ихтималы бар дигән сүз монысы. Россия дә читтә кала алмый. Әлегә конфликт борнау стадиясендә томаланды шикелле.

Согуд корольлегендә хәл яңадан кискенләште. Җомга көнне Йәмән гыйсъянчылары нефть державасының Җиддәдәге инфраструктурасына чираттагы ракета һөҗүме ясадылар. Янгын чыгып, ут бер резервуардан икенчесенә күчте. Согуд Гарәбстаны моңа гарәп илләре коалициясенең хәрби операция башлавын игълан итеп җавап бирде. Йәмәннең Кызыл диңгездәге порт шәһәренә авиаһөҗүмнәр ясалды. «Әль-Мәсира» Йәмән телеканалы белдерүенчә, медицина үзәге зыян күргән.

Европа театрында тагын бер хәрби конфликт куркынычы пәйда булды: Сербия Косовога каршы коралллы һөҗүм ясау ниятен игълан итте һәм калканлы техникасын хәрәкәткә китерде. Франция үзенең атом-төш коралллы көчләрен хәрби хәзерлек хәленә китерүе турында белдерде. Атом-төш очлыклы ракеталар белән коралланган өч су асты көймәсе ачык диңгезгә чыкты. Бу – французларның соңгы утыз елда беренче тапкыр шулай кыланулары.

Россиядә

ХӨКҮМӘТ ЯРДӘМГӘ АШЫГА

Тышкы басым көчәйгән шартларда Россия җитәкчелеге аңа каршы тору юлларын эзли. Санкцияләрне әйләнеп үтү шактый катлаулы, күп вакыт хәтта мөмкин дә түгел. Мәскәү белән аркадашлыкны сакларга теләгән илләр дә сәүдә элемтәләрен өзәргә мәҗбүрләр. Сербия Сәүдә-сәнәгать палатасында үткән атна азагында илдән Россиягә товарлар озатып торуны туктатырга туры киләчәген әйттеләр. Евросоюз чолганышындагы бу төбәктән кәрваннар уздыру – бик катлаулы эш чөнки. Товар сатып алу өчен финанслар да кирәк бит әле. Швед икътисадчысы, Көнчыгыш Европа икътисады буенча белгеч Андрес Ослунд Көнбатыш илләрендә Россиянең 1 триллион долларлык байлыгы бар дип белдерә.

7 апрель көнне федераль хөкүмәт Дәүләт Думасында еллык отчет бирергә җыена. Премьер-министр Мишустин шуңа әзерлек кысасында парламент фракцияләре вәкилләре белән очрашулар үткәрә. Бу юлы Думада гадәти отчет кына тыңланмаячак, ә гражданнарны яклауның һәм аларның керемнәрен арттыруның нәтиҗәлерәк механизмнарын тәкъдим итәргә җыеналар.

Үткән атнада премьерның ЛДПР фракциясе вәкилләре белән очрашуы булды. Очрашу, мәгълүм сәбәпләр аркасында, Жириновскийдан башка гына үтте, билгеле. Мишустин илнең соңгы вакытларда тиңе булмаган тышкы басым шартларында яшәвен искәртте. Мондый шартларда икътисадның тотрыклылыгын саклау өчен, ашыгыч чаралар күрергә туры килә. Сүз социаль түләүләрне, пенсияләрне, пособиеләрне арттыру турында да, предприятиеләргә эчке базар өчен социаль әһәмиятле товарлар җитештерүне җайга салырга һәм арттырырга булышу хакында да бара. Аңлашыла инде: товар кытлыгы булса, акчалата ярдәмнең бер файдасы да булмаячак, ярдәмне инфляция ашап бетерәчәк. Кесәгә миллион сум акча тыгып йөргән бар, ул акча белән байлыкка ирешеп кенә булмады. Очрашуда сүз халыкны дарулар белән тәэмин итү, криптовалюталарны әйләнешкә кертү, авыллар арасында юллар төзү турында да барды. Цифрлы валюталар ярдәмендә Россия санкцияләрдән котылырга да тели иде. Әмма АКШ җитәкчелегендәге Көнбатыш бу ниятка аяк чалырга тырыша.

Хөкүмәт җитәкчесе белән очрашуга «Яңа кешеләр» («Новые люди») фракциясе вәкилләре дә килде. Фракция лидеры Алексей Нечаев бизнесны тикшерүләргә кертелгән мораторийның әһәмиятенә аеруча нык басым ясады. Эш урыннарын саклап калу, яңа технологик һәм финанс чылбырлары урнаштыру белән мәшгуль булган бизнесны тикшерүләр уздырып җәфалауның зыянлы булуын җиткерергә тырышты.

Икътисадның тотрыклылыгын тәэмин итү өчен планда 200дән артык инициатива бар икән. Дәүләт Думасы ике дистәдән артык закон кабул иткән. Хөкүмәт тагын утызны әзерләгән. Бу чараларның кая таба алып баруы якындагы өч-дүрт айда күренер, мөгаен.

ТЕЛЕФОН БЕЛӘН ТЕЛЕВИЗОР ГЫНА ТҮГЕЛ!

Укучыларның кәефе шәп! Ник дигәндә, 28 мартта язгы каникул башланды. Алар аны диванда ятып кына үткәрергә җыенмый. Кемдер авылга әби-бабайга кунакка кайтачак, кемдер театрга, зоопаркка барачак. Бер атна вакыт рәхәтләнеп ял итәргә җитәрме?

Казанда яшәүче Хамедлар гаиләсе биш бала тәрбияли. Өчесе мәктәптә укыса, икесе бакчага йөри. Әниләре Гөлия әйтүенчә, балалары каникулны күптән көтеп алган. Кечкенәләре Йосыф, Зәйнәп, Сафия, көймәләр ясап, гөрләвектә йөздереп караган инде. Барысы да канәгать калган. Авылга кайткач та кабатламакчылар.

– Питрәч районының Шәле авылына, әби-бабайга кунакка кайтырга җыенабыз. Балалар белән елга буйларын әйләнеп кайтачакбыз. Ташу китсә, аны күзәтербез, көймәләр агызырбыз. Тик кояшы гына чыксын инде. Урманга да барып кайтасы килә бер. Табигатьтә йөреп, саф һава сулау үзе бер рәхәт, – ди Гөлия Хамед. – Рамазан аен көтәбез. Шуңа күрә кичләрен бергәләп, әлеге саваплы ай, ураза турында сөйләшәбез. Балаларга бу да кызык.

Шәһәр баласы, авылга кайтып, каникулда яңа сауган сөт эчәр. Гадәттә, аларга тансык бу. Арча районының Иске Кырлай авылында яшәүче Данил абый Әхмәтҗанов исә башка кызыксындыру чарасын тапкан. Ул аларны «баллы мамык» белән сыйлаячак. Үзе шундый җайланма ясаган икән. Хәзер оныклар да бабай янында ешрак бөтерелә башлаган.

Хезмәттәшебез Зөһрә Садыйкова да язгы каникулны балалары белән бергәләп уздыра.

– Каникул алдыннан гына улыбызга операция булды. Шул сәбәпле, аңа

Илдар Мөхәммәтҗанов

вакытын күбрәк өйдә уздырырга туры киләчәк. Сыйныфташлары музейга бара. Беренче сыйныфта укучы кызыбыз Азалиянең рәсем түгәрәкләре дәвам итә. Кичә кафеда тәмле ризыклар белән сыйланып кайттык. Кызым белән теш табибына язылган идек. Китапханәгә барырга да ниятләп торабыз. Шимбә көнгә театрга билет алдым. Кыскасы, башкарасы эшләр күп, вакыт кына җитсен, – ди Зөһрә Садыйкова.

Музей, театрларның да ишекләре ачык. Казан Кремле укучылар өчен 4 апрельгә кадәр программа әзерләгән. Әйтик, балаларны «Манеж» күргәзмәләр залында – «Анимация тылсымы» һәм «Аниматор сере», Благовещенск соборы тарихы музеенда – «Преданья старины глубокой» чаралары, Ислам мәдәнияте музеенда – «Пыялага рәсем төшерү», «Татарча гаилә вензеле» мастер-класслары, «Кол Шәриф коды» квесты, Татар халкының дәүләтчелеге тарихы музеенда «Кызыл матбугат сере» квесты көтә. Сыйныф белән «Татарча кунакчыллык» яки «Казан Кремле – балаларга» экскурсия турларына барырга, «Эрмитаж-Казан» үзәгендә рәсем сәнгате күргәзмәсен карарга, Татарстанның табигать тарихы музеенда динозаврлар калдыкларын күрергә мөмкин.

1–3 апрельгә кадәр Татарстан Милли музеенда «Бүләк тапшыру көннәре» узачак. Музейга борынгы һәм истәлекле әйберләр, сәнгать предметлары, архив фотолары һәм документлар, сирәк китаплар кабул ителә.

Яшьләр эшләре министрлыгы мәгълүматларына караганда, язгы каникул көннәрендә Татарстандагы лагерьларда 16 меңнән артык бала ял итәчәк. 5148 бала шәһәр читендә сәламәтлеген ныгытачак. Калганнары исә Татарстанның Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы көндезге лагерьларда шөгыльләнәчәк.

Сәрия МИФТАХОВА

ЯЗГЫ КАНИКУЛНЫ НИЧЕК УЗДЫРЫРГА?

ТАБИГАТЬНЕ КҮЗӘТЕГЕЗ
Сыерчыклар кайтмаганмы, ташу китмәгәнме, тау битендә үләннәр чыга башлаганмы... Балаларыгыз белән табигатькә чыгыгыз. Гөрләвектә көймә йөздереп, балачак хатирәләрен яңартыгыз.

ҮСЕНТЕЛӘР УТЫРТЫГЫЗ
Тәрәзә төпләрендәге гөлләрне яңартып, туфракларын алыштыра аласыз. Яшелчә үсентеләре утыртыгыз.

ФОТОГА ТӨШЕГЕЗ, АЛЬБОМ ЯСАГЫЗ
Гаиләгез белән истәлекле урыннарга барып, рәхәтләнеп фотога төшегез. Бергәләп зоопаркка барасызмы, әллә урамда күгәрченнәр ашатасызмы, күлгә үрдәкләр карарга барасызмы... Менә шул мизгелләрне фотосурәттә истәлек итеп калдырыгыз. Телефоныгызда сакланган фотоларны альбом итеп ясатып, бергә утырып хатирәләрне барлый аласыз.

КИНО КАРАГЫЗ, СПЕКТАКЛЬГӘ БАРЫГЫЗ
Гаиләгез белән яраткан киногa, спектакльгә барып кайтыгыз.

ӨСТӘЛ УЕННАРЫ УЙНАГЫЗ
Лото, домино, шашка, шахмат, хоккей, футбол кебек өстәл уеннары уйнарга мөмкин. Бөтен гаиләгез белән катнашсагыз, тагын да күңеллерәк булыр.

БЕРГӘЛӘП РИЗЫК ӘЗЕРЛӘГЕЗ
Күптән пешерергә хыялланып йөргән ризыгыгыз бардыр, бәлкем. Тортмы, рулетмы, бәлешме, манты, өчпочмакмы... Рецептын сайлагыз да бергәләп пешерегез. Тәмләп чәй эчүгә ни җитә!

КУЛ ЭШЛӘРЕ ТУРЫНДА ОНЫТМАГЫЗ
Малайлар әтиләре белән сыерчык оясы, кошларга җимлекләр ясый, кызлар бәйләү, тегү, чигү эшләренә өйрәнә ала. Кызлар арасында хәзер чүпрәк сумкалар тегү популяр.

КИЕМ ШКАФЫН ТӘРТИПКӘ КИТЕРЕГЕЗ
Кирәкмәгән киемнәрдән арынып, тәртип урнаштырыгыз. Кечерәеп калган киемнәрне танышларыгызга, мохтаҗларга бирә аласыз.

САМАВЫРЫ – КӘГАЗЬДӘН, ЧӘЕ – ҮЛӘННӘН

Авыл капкасы

Заманында Балтач районында бердәнбер хатын-кыз зоотехник булган, үзе турында искиткеч матур фикерләр калдырып, берничә ел элек лаеклы ялга киткән, Чутай авылында яшәүче Гөлзифа Нәҗипованы бик әйбәт беләм дип саный идем. Күп аралаштык, эшен булдырып эшли торган, бик тә хыялый, искиткеч белемле булганга, аны әле эштән җибәрми тартыштылар, «киттем» дигәннән соң да ничә тапкыр «кайтты» дип беләм.

Була бит шундый кешеләр: ул кайда гына эшләсә дә, «үз урынында» кебек тоела. Гөлзифа да шундый булган. Сөт җыючы булып эшләгән – гаделлеге, төгәллеге белән аерылып торган. Фермага хисапчы итеп куйганнар – Казаннан, министрлыктан килгән тикшерүчеләр дә аны «бик көчле белгеч» дип бәяләгән. Баш зоотехник булып эшләгәндә дә районда иң көчле, фанат белгечләрнең берсе була. Гөлзифаны якыннан белүчеләр аннан әле тагын бер дигән укытучы, журналист, мәдәният хезмәткәре... һәм тагын әллә кемнәр чыгар иде диләр. Күпме кешене үз һөнәренә өйрәтүен, сөйләү осталыгын, тәрбиялелеген, бик тә хисле, иҗади булуын күздә тотып әйтәләр. Сценарийлар авторы, нәфис сүз остасы, кирәк икән, җырчы, шагыйрь, артист, кирәк икән, оста оештыручы (урамнары белән җыр-сәнгатькә гашыйк кешеләрне туплап, авыллар буенча концертлар куюда да башлап йөрүче Гөлзифа)... Сөбханалла, бер кешедә күпме сәләт!

Билгеле, көйле генә барса, тормыш буламыни инде ул?! Гөлзифаның да куркыныч авырудан югалып, сынар чиккә җиткән чаклары була. «Ире Рәис шундый зур терәк булды ул елларда, аңлады да, саклады да, бу чирне икесе бергә җиңделәр», – дип искә ала авылдашлары. Тиктормас Гөлзифа үзе дә өйдә утырган ул елларда кул эшләре белән җанына дәва таба. Бәйли, тегә, чигә. Түбәтәйләрен, ул чорда бик данлыклы булган челтәрле тәрәзә пәрдәләрен бик яратып алалар. Бер өйрәнгәч, кул эшләреннән аерыла алмый инде ул. Аларны яңа шөгыльләре белән баета гына. Бисердан әллә ниләр эшли, аннан замш һәм губкага охшаш фоамарин дигән материалдан кабатланмас чәчәкләр ясый башлый. Үзе өчен генә, бүләккә дип тотынган кул эшләнмәләрен күргән кешеләр заказлар бирә башлый. Ә ул тора-бара танышларын гади газета битләреннән самавыр-чынаяклар, ваза, гөл чүлмәкләре, шкатулка-тартмачыклар үреп сокландыра.

2020 елдан Гөлзифа һәм аның командасында – ягъни гаиләсендә яңа шөгыль барлыкка килә. Алар бергәләп үлән чәйләре ясыйлар. Инде Татарстан күләмендә танылып та өлгергәннәр!

– Без элек тә үләннәрне күп җыя, үлән чәйләре эчә идек, – дип дәвам

итә Гөлзифа. – Кунакка кайткач, оныгыбыз үлән чәе эчте дә, нигә без аны сатмыйбыз, дип сорады. Башта көлештек, ә аннан чыннан уйлана калдык, чөнки безнең якларда бик күп шифалы үләннәр үсә.

Хәзер инде Нәҗиповлар да, Казандагы кызлары Рәмзия гаиләсе дә иртә яздан көзгә кадәр шифалы үләннәр, җиләк-җимешләр җыю, киптерү белән мәшгуль. Яфрагыннан, бөресеннән башлап, һәммәсен кулланалар. Рәмзия исә, укытучылык эшен ташлап, үзмәшгуль булып теркәлеп, чәй җитештерүгә ныклап алынган. Үз брендларын булдырып, унөч төрле үлән чәе җитештерәләр. Алар матур итеп төрелгән, чәйнең исеме ике телдә язылган. Арада Президент чәеннән башлап, Килен чәе, Әбиемнең кишер чәе, Бакча чәе, Кышкы чәй, Юлчы чәе, Мунча чәе, Йокы чәе, Шүрәле чәе, Көтүче чәе... дигәннәре дә бар. Кайсы җылыта, кайсы тынычландыра, кайсы энергия бирә, кайсы...

Чәйләрне, шулай ук төрле үләннәрне дә Казанда фермерлар кибетләрендә, агропаркта да саталар, ресторан-кафелар белән дә хезмәттәшлек итәләр, чәйләрен тәмләп карау чаралары да үткәрәләр, күргәзмәләрдә катнашалар. Социаль челтәрләрдә аларны «Тын авыл үләннәре» («Травы тихой деревни» – чәйләренең бренды да бу) төркеме буенча беләләр. Чәйләре Россия буйлап таралып, төрле шәһәрләрдән бик күп уңай кайтавазлар, рәхмәт сүзләре дә алганнар.

– Чутайда тутырылган дип язылган чәебез Италиягә кадәр барып җитте, аннан да рәхмәт сүзләре кайтты, – ди Гөлзифа. – Чәйләребезне генә түгел, җиләк-җимешләрдән киптереп ясалган коры компотларны, какларны, 100–200 граммлы махсус банкаларга тутырылган кайнатмаларыбызны да бик яратып алдылар. Үзебез дә аптырап куябыз хәтта...

«Акча аяк астында, иелеп алырга гына кирәк», – дигәнгә бер мисал инде бу кадәресе. Һәм сәләтле кеше һәрьяктан сәләтле дигәнгә дә менә дигән өлге.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Авылда эш көтә

Яшьләр кайтмый, авылда эшлиселәре килми. Мондый сүзләрне еш ишетергә туры килә. Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясе авыл хуҗалыгына ел саен йөзләгән белгеч әзерли. Ул белгечләр, укып бетергәч, кайда эшләр? Авылга кайтырга телиләрме? Моны үзләреннән белештек.

Казан дәүләт ветеринария медицинасы академиясендә эш урыннары ярминкәсе узды. Студентларны республиканың иң эре авыл хуҗалыгы предприятиеләре белән таныштырдылар.

– Әлеге ярминкә безнең академия тарафыннан 20 елдан артык үткәрелә. Аның максаты – студентларга уку йортын тәмамлаганнан соң, эшкә урнашу мөмкинлекләре турында сөйләү, эш бирүчеләр белән таныштыру. Алар арасында – агрохолдинглар, эшкәртү сәнәгате оешмалары, дәүләт ветеринария структуралары һәм органнары, – ди академиянең укыту һәм тәрбия эшләре буенча проректоры Данил Мингалиев.

Аның әйтүенчә, эш урыннары ярминкәсеннән тыш, академия студентлар өчен уку практикасы да оештыра. Икенче курстан башлап яшьләр тәҗрибә туплый. Укулары тәмамлангач, яшь белгечләрнең күбесе нәкъ менә практика узган оешма һәм хуҗалыкларга юл тота. Узган ел республикадан булган 98 студентның 89ы эшкә урнашкан.

– Илдәге вазгыять авыл хуҗалыгы, азык-төлек куркынычсызлыгы тармакларының әһәмиятен күрсәтте. Терлекчелекне, авыл хуҗалыгын үстерергә теләгән яшь кадрлар һәрвакыт кирәк, – ди Данил Мингалиев.

Ветеринария академиясенең «Биотехнологияләр һәм стандартлаштыру» факультетында зоотехния, стандартлаштыру һәм метрология, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү, менеджмент кебек юнәлешләрне үзләштерәләр.

Гүзәл Зәйнуллина 4 нче курста укый.

– Бу өлкәне кечкенәдән үк терлекләр белән эшләргә хыялланганга күрә сайладым. Максатчан рәвештә бу уку йортына кердем, инде үзем теләгән эш урынымны да сайлап куйдым. Саба районының Югары Шытсу авылында зоотехник булып эшләячәкмен, – ди ул.

Гөлназ Шәрәфиева да биотехнология һәм стандартлаштыру факультетының 4 нче курсында белем ала. Авылда үз хуҗалыгын булдырырга тели.

– Кечкенәдән йорт хайваннарын яраттым. Шуңа зоотехник һөнәрен сайларга булдым. Әти белән әни дә моңа каршы килмәде. Уку дәверендә практиканы Мамадыш, Әтнә районнарында үткәнем бар. Хыялым – укуны уңышлы тәмамлап, авылда үз хуҗалыгымда эшләү, – ди Гөлназ.

Таһир Гарифҗанов ветеринария медицинасы факультетының 5 нче курсында укый. Укып бетергәч, Актаныш районының Аеш авылында «Нигез» хуҗалыгында эшләргә җыена.

– Безнең гаиләдә барлык ир-ат терлекчелек белән шөгыльләнә. Бабам – терлекләрне орлыкландыручы, ә әти зоотехник булып эшли. Балачактан ук алар белән фермага йөрдем һәм мал табибы булырга хыялландым, – ди егет. – Аннары мәктәптә укыганда «Нигез» хуҗалыгына эшкә йөри башладым. Җитәкче белән инде сөйләшеп куйдык: эшкә килермен, биредә мал табибы булып эшләячәкмен.

Ләйсән САФИНА

«КЫЗЫЛ СЫЗЫК»ТАН ЧЫГУ

УКРАИНАДАГЫ МАХСУС ХӘРБИ ОПЕРАЦИЯ ТУРЫНДА 10 СОРАУГА ҖАВАП

«Российская газета» Украинадагы махсус хәрби операция турында халыкны иң нык кызыксындырган сорауларга җавап биргән. Без дә, шуларның иң мөһимнәрен туплап, укучыларыбыз игътибарына тәкъдим итәбез.

rg.ru

1 Без Украинада нишлибез?

Президент Владимир Путин 21 февральдәге мөрәҗәгатендә белдергәнчә, узган елның декабрендә Европада иминлекне саклау, НАТОны киңәйтмәү турында АКШ һәм аның союзниклары белән тагын бер тапкыр үзара килешүгә омтылыш ясалды. Әмма бу юлы да уртак тел табылмады.

Тарихтан белүебезчә, 1940 елда һәм 1941 ел башында СССР сугышны булдырмау яки һич югы кичектереп тору өчен төрле чаралар белән тырыша. Әмма Бөек Ватан сугышы алдыннан агрессорны акылына китерергә маташу хата булып чыга һәм бу халкыбызга бик кыйммәткә төшә. «Мондый хатаны кабатламаячакбыз», – дип белдерде Владимир Путин. Эш шунда: тарихи территорияләребез тирәсендә безне дошман күргән «анти-Россия» булдырылды. Ул тулысынча тышкы контрольлеккә алынып, НАТО илләренең коралы көчләре һәм коралы белән бик нык тәэмин ителде.

«Мәнфәгатьләребезгә генә түгел, дәүләтебезгә, аның мөстәкыйльлегенә дә янау бу. Кат-кат телгә алынып килгән шул «кызыл сызык» бу. Алар аннан чыкты», – дип йомгак ясады Россия Президенты.

Асылда Россиягә карата соңгы елларда бик җентекләп планлаштырылган мәгълүмати операция үткәрелә. АКШның соңгы атналардагы мәгълүмати сәясәтенә килсәк, Америка Гыйракка бәреп кергәндә дә шундый ук хәл күзәтелде. Саакашвилиның да Цхинвалга һөҗүме алдыннан, америкалыларга ияреп, шулай кыланып алуын бик яхшы хәтерлибез. Россиянең Украинага һөҗүм итәсе көнен АКШ һәм Британиянең көннең-көнендә тәкрарлап торуы дөнья җәмәгатьчелеген агрессорның нәкъ менә Мәскәү булып торуы турында фикергә этәрде. АКШ һәм НАТОның безнең белән уртак тел табу уе юк иде – алар беренче булып һөҗүмгә әзерләнде. 150 мең кешедән торган гаскәрнең Донбасс һәм Кырымга бәреп керергә җыенуы белән беррәттән, НАТО көчләренең Россиягә ракета һөҗүме ясау планы да булгандыр. Шулай икән, Президент Путинның, 1941 елның июнендә фашистлар Германиясенең кинәт һөҗүменә бәйле хәлнең кабатлануына юл куярга ярамый, дигән сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Махсус операция башлап, Донбасста, Украина һәм Россиядә йөзләрчә мең кешенең гомерен саклау белән беррәттән, Өченче Бөтендөнья сугышы башлануны да булдырмыйча калганбыздыр, дип уйларга тулы җирлек бар.

2 АКШ белдергәнчә, НАТО да, Кушма Штатлар үзләре дә Россиягә янамый. Шуңа күрә, янәсе, Мәскәүнең барлык шикләнүләре урынсыз. Чыннан да шулаймы?

Россия Иминлек советы мәгълүматларына караганда, соңгы вакытларда Европада АКШның 60 мең хәрби хезмәткәрдән, 200 танк һәм 150 хәрби самолеттан торган бик зур коралды көчләре төркеме булдырылган. Моннан тыш соңгы елда Россия чикләре янында Америка бомбардировщикларының очышлары 40 процентка арткан. Калининград өлкәсе һәм Кырымда НАТОның һава разведкасы ике тапкыр диярлек көчәйтелгән. Кара диңгездә НАТО корабларының провокацияләр ясаудан туктаганы юк. Россиягә каршы сугышка әзерләнү, димичә, моны тагын ничек дип атарга мөмкин?

Шулай итеп, «акыллы» Европа, 1941 елдагы кебек, 2022 елда янә «Кызыл армия»гә каршы сугышка «керде». 1941 елда ул Гитлер Германиясе артыннан барса, хәзер аны АКШ җитәкли. 2022 елның гыйнварыннан февраль уртасына кадәр, ягъни махсус операция башланганчы, Украинага Көнбатыш илләреннән 50ләп хәрби транспорт самолеты төшеп утырган: алар 2 мең тонна корал, сугыш кирәк-ярагы, саклану чаралары китергән.

Бигрәк тә АКШ тырышкан: 2014 елдан бирле Кушма Штатлар Украинага 2,7 миллиард долларлык хәрби ярдәм күрсәткән. 17 мартта Байден Украинага тагын 1 миллиард долларлык корал җибәреләчәген белдерде. Ягъни АКШ, чыннан да, Украинада соңгы украин солдатына кадәр сугышырга әзер, дигән сүз.

3 Киев һәм аның Көнбатыштагы дуслары фикеренчә, Донбасс мәсьәләсен сөйләшүләр юлы белән дә хәл итәргә мөмкин иде. Дөрес фикерме бу?

Россия 8 ел буе Киевны Донбасс белән үзара килешергә өндәп килде. Әмма Украина хакимияте, үз халкын «террорчы» дип белдереп, аның белән сөйләшергә теләмәде. Хакимияттәгеләр Минск килешүләрен үтәмәячәкләрен бөтен халык ишетерлек итеп әйткәч, бу мәсьәләгә нокта куярга туры килде. «Россия Донбасс халкына карата геноцидка башка түзеп тора алмый. Минск килешүләре юкка чыкты», – дип белдерде Президент Путин. Аның әйтүенчә, Европа Киевны «Минск-2» килешүен үтәүгә мәҗбүр итә алмады, шуңа күрә Донецк һәм Луганск республикаларын танудан башка чара калмады. Ә Минск килешүләре республикаларны тануга кадәр инде әллә кайчан ук «үтерелде».

4 Ни өчен Россия махсус хәрби операция башлады? Берничә көн алдан гына, мондый хәл булмаячак, дип белдерелгән иде бит.

Украинага гаскәрләр кертү турында карар, чыннан да, бик ашыгыч төстә кабул ителде. Сәбәбе – Украинаның Донбасс һәм Кырымга бәреп керергә әзерләнүе турында, шулай ук Украинаның Россиягә карата атом-төш коралы куллану ихтималы турында мәгълүматлар алыну.

5 Украинаның атом-төш коралы бармы?

Исегезгә төшерәбез: нәкъ менә Зеленский 20 февраль көнне Мюнхенда, ягъни Россиянең Луганск һәм Донецк республикалары бәйсезлеген тануына бер көн кала, Украинаның Будапешт меморандумыннан чыгарга һәм үзен саклау өчен атом-төш коралын эшләргә әзер булуын белдерде.

Бу вакытта Киев инде атом-төш коралын эшләүгә барысын да әзерләп куйгандыр, дип уйларга кирәк. Беренчедән, Украинаның Россия тарафына берничә тапкыр җибәреп караган «Точка-У» ракеталары (СССРдан соң анда кимендә 90 шундый ракета комплексы калган) бар. Аларны атом-төш коралы белән дә корыргa мөмкин. Икенчедән, Украина «Южмаш» һәм «Южное» ракета конструкторлык бюроларына ия. Аларда баллистик ракеталар җитештерүне яңартып җибәрергә мөмкин. Советлар Союзыннан калган атом-төш тикшеренүләре белән шөгыльләнүче фәнни-техник институтлар, шулай ук атом электр станцияләре челтәре эшләп килүен онытмыйк тагын. Боларның барысы да «пычрак» атом бомбасын да, шулай ук Көнбатыштагы дуслар ярдәмендә «гадәти» атом-төш ракеталарын да җитештерү мөмкинлеге бирә. Әле тагын Киев режимының Пентагон белән атом-төш коралы буенча гына түгел, биологик корал эшләү буенча да иңгә-иң торып эшләгәнлеге ачыкланды. Россия Оборона министрлыгы рәсми вәкиле Игорь Конашенков белдергәнчә, Украина биолабораторияләре хезмәткәрләреннән 24 февральдә аеруча хәтәр патогеннарның ашыгыч төстә юкка чыгарылганлыгы турында документлар алынган. Биредә чума, түләмә, холера һәм башка куркыныч чирләр китереп чыгаручы вируслар турында сүз бара.

6 Украина хәрбиләре ни өчен Путинны ишетмәде?

Эш шунда: Донецк, Луганск чикләрендә тупланган Украина хәрби көчләре (ВСУ) һәм националистлар гвардиясе Донбассны тиз генә алмакчы иде. Хәер, Украинаның дистәләрчә мең хәрбие дә – асылда шул ук националистлар. Донецкида яшәүче тыныч халыкка көннең-көнендә туплар атып торган ВСУ артиллеристлары яки ракетачыларын боерык үтәүче гади хәрбиләр дип кенә әйтергә тел әйләнми.

Донецк Республикасы Халык милициясенең рәсми вәкиле Эдуард Басурин, махсус операция башланырга бер атна кала, ВСУдан урланган Донбасска һөҗүм картасын фаш итте. Анда артиллерия, ракета, авиация һөҗүме, шуннан соң «Төньяк», «Көньяк» һәм «Көнчыгыш» төркемнәре һөҗүме планнары бик төгәл күрсәтелгән.

Шул ук вакытта Донецк, Луганск һәм тагын берничә шәһәрне һөҗүм итмичә генә камалышка алуның, ыгы-зыгыда Россия чигендә НАТОның тынычлык урнаштыручы көчләрен төшереп утыртуның күздә тотылганлыгы ачыкланды.

Инде килеп, 6 мартта ВСУның Донбасс һәм Кырымга 8 март көнне бәреп керергә әзерләнгәнлеге мәгълүм булды.

7 Украина нацистлары – кемнәр ул?

2014 елгы «мәйдан»нан соң Украина неонацистлары оешмалары җитәкчеләре һәм Донбасста сугышкан боевиклар, Югары Радага үтеп, Украина хөкүмәте һәм президенты офисында зур вазыйфаларга ия булды.

Бу адәмнәрнең украин булулары белән горурлануы үзләрен Донбасста яшәүчеләрне кешегә дә санамаслык дәрәҗәгә җиткергән. Украина башкисәрләре Донецк һәм Луганск республикаларында 8 елга сузылган геноцидта 14 меңгә якын кешене үтергән. Шуның 500дән артыграгы – балалар.

Киевның 2014 елдан бирле үз халкы белән алып барган сугыш алымнары гитлерчыларның оккупацияләнгән җирләрдәге вәхшилегеннән аерылмый диярлек. Мариуполь, Харьков һәм кайбер башка шәһәрләрдә яшәүчеләрне тере калкан сыйфатында куллануга да кагыла бу. Мондый алымны хәзер Сүриядәге ИГИЛ (Россиядә тыелган террорчы оешма) боевиклары гына куллана.

Украина – Көнбатышның «анти-Россия» проекты гына түгел. Соңгы 30 елда рус телле халык өчен чын мәгънәсендә хезмәт-тәрбия концлагерена әйләнде ул. Шушы еллар эчендә «москаль» (мәскәүле) һәм «кацап»ларга (мәскәүле булмаганнар) карата чиктән тыш нәфрәт тудырылып, 2014 елда ул соңгы чиккә җитте. Нәкъ менә шул чагында Украина авиациясе Донецк, Луганск шәһәрләрен утка тотып, балалар һәм хатын-кызларны үтерде. Ә националистлар, Одессаның Профсоюзлар йортында кешеләрне тереләй яндырып, янәсе, «сепар» һәм «колорадо»ларны үтерәбез, дип ыржайды. Соңгы 8 ел дәвамында Украинада Россиягә карата ирекле фикер йөртү, аңа аз гына теләктәшлек белдерү дә катгый төстә бастырылып килде.

Киев режимы белән килешмәүчеләр төрмәләргә утыртылды, судсыз-нисез җәзаланды, үтерелде. Халыкка, аеруча яшьләргә нацистлык идеяләре үтә нык сеңдерелде. Нәкъ менә шул сәбәпле хәзер ВСУда гына түгел, «Азов» нацистлары, башка националистик батальоннар сафларында руслар, хәтта Донбасста яшәүчеләр дә бар.

8 Ни өчен Россия хәрби операцияне 2014 елда үткәрмәде? Безгә барыбер санкцияләр салынды бит.

Ул чагында илебез хәзер кертелгән санкцияләргә әзер түгел иде. Икътисад аларны күтәрә алмаган булыр иде. Моннан тыш 8 ел эчендә армия һәм флотны заманча техника һәм корал белән, шул исәптән югары төгәллектәге корал белән җитәрлек күләмдә тәэмин итүгә ирешелде.

9 Утыз ел буе бандерачылык пропагандасы алып барылган Украинада күпчелек халыкның Россияне беркайчан да кабул итмәячәге, шуңа күрә алга таба безгә партизан сугышларына һәм террорлык актларына дучар булып яшәргә туры киләчәге турында фикерләр ишетелгәли. Чыннан да, шулай булырмы?

Юк. Мәсәлән, «Мәйдан» «байрагы», русларны кыралмаган вертолетчы Надежда Савченконы хәтерлисездер. Ул Россия журналистларын үтергән өчен төрмәдә утырды. Амнистиягә эләгеп, Украинага әйләнеп кайткач, фикерен тамырдан үзгәртте.

10 Алга таба ничек булачак?

Илдә тынычлык урнаштырылганнан соң ирекле сайлау үткәрү күздә тотыла. Җинаятьчел режимга кагылышы булмаган җитәкчене Украина халкы үзе сайлаячак. Украина дәүләт буларак сакланып калачак. Әмма нинди статуста булачагы әлегә билгесез: бу кадәресе сөйләшүләр барышында хәл ителергә тиеш.

АКШ кайсы илләрне бомбага тотты?

Корея һәм Кытай	1950–1953 (Корея сугышы)
Гватемала	1954
Индонезия	1958
Куба	1959–1961
Гватемала	1960
Конго	1964
Лаос	1964–1973
Вьетнам	1961–1973
Камбоджа	1969–1973
Гватемала	1967–1969
Гренада	1983
Ливан	1983, 1984
Ливия	1986
Сальвадор	1980
Никарагуа	1980
Иран	1987
Панама	1989
Гыйрак	1991 (Фарсы култыгында сугыш)
Гыйрак Күвәйт	1991
Сомали	1993
Босния	1994, 1995
Судан	1998
Әфганстан	1998
Югославия	1999
Йәмән	2002
Гыйрак	1991–2003 (АКШ/ Бөекбритания даими рәвештә)
Гыйрак	2003–2015
Әфганстан	2001–2015
Пакьстан	2007–2015
Сомали	2007–2008, 2011
Йәмән	2009, 2011
Ливия	2011, 2015
Сүрия	2014–2015

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

ВАЗАНОВ АНДРЕЙ ЮРЬЕВИЧ

(24.07.1962 – 25.03.2022)

Татарстан Республикасы җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды.

Юстиция генерал-майоры, элекке эчке эшләр министры урынбасары – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Баш тикшерү идарәсе җитәкчесе Вазанов Андрей Юрьевич 25 март көнне 60 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте.

Андей Вазанов 1962 елның 24 июлендә Казан шәһәрендә туган. 1984 елда Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң Казан шәһәре Киров районы башкарма комитетының эчке эшләр бүлегендә тикшерүче вазыйфасына эшкә алынган. 15 ел дәвамында Татарстан Республикасы эчке эшләр органнарының тикшерү бүлекчәләрендә төрле вазыйфаларда хезмәт куйган.

Андрей Юрьевич 1999–2011 елларда эчке эшләр министры урынбасары – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Баш тикшерү идарәсе җитәкчесе булып эшләде. Аның җитәкчелегендә тикшерү органнары эшендә беренче чиратта җинаятьчелеккә каршы көрәшне көчәйтүгә юнәлдерелгән комплекслы чаралар үткәрелде. Ул урыннардагы тикшерү бүлекчәләре җитәкчеләренә хезмәт эшчәнлеген оештыруда һәм авыр җинаятьләрне ачуда зур ярдәм күрсәтте. Аның катнашында Казан, Чаллы, Чистай, Баулы, Нурлат шәһәрләрендә җәмәгатьчелектә зур резонанс тудырган җинаять эшләре кузгатылды.

Андрей Вазанов Төньяк Кавказда террорчылыкка каршы операция үткәрелгән урыннарда берничә тапкыр булып кайтты. Анда куелган бурычларны үтәүдә үзенең оештыру һәм профессиональ сыйфатларын иң яхшы яктан күрсәтте.

Эчке эшләр органнарында хезмәтен тәмамлаганнан соң төрле предприятиеләрнең иминлеген һәм хокукый эшчәнлеген тәэмин итү структураларында эшләде.

Эшенә тугрылыгы, ташып торган көч-энергиясе, үз алдына куелган бурычларга ирешүдәге ныклыгы, кешеләргә карата ихтирамлы мөгамәләсе һәм җаваплылыгы аңа зур абруй-хөрмәт китерде.

Андрей Юрьевичның хезмәттәге казанышлары югары дәрәҗәдәге бүләкләр белән билгеләнде. Алар арасында – Почет ордены, «Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале, «Татарстан Республикасының атказанган юристы» мактаулы исеме, «Җәмәгать тәртибен саклаудагы аерым хезмәтләр өчен», «Хезмәттәге фидакарьлек өчен», «Казанның 1000 еллыгы истәлегенә», «Георгий Жуков», «Батырлык һәм гуманизм өчен» медальләре, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Мактау грамоталары.

Вазанов Андрей Юрьевичның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

Р.Н. Миңнеханов, А.В. Песошин, Ә.Ә. Сәфәров,
Р.В. Гыйльманов, И.Р. Метшин, А.В. Хохорин,
И.С. Нәфыйков, И.И. Гыйлаҗев, В.А. Сәлимов

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгы лаеклы ветераны, отставкадагы юстиция генерал-майоры, элек Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры урынбасары вазыйфасын биләгән **Вазанов Андрей Юрьевич**ның 60 нчы яшендә вафат булуын хәбәр итә.

Андрей Вазанов 1984–1999 елларда Татарстан Республикасы эчке эшләр органнарының җирле һәм структур тикшерү бүлекләрендә төрле вазыйфаларда хезмәт куйды. 1999–2011 елларда Татарстан эчке эшләр министры урынбасары – Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Баш тикшерү идарәсе җитәкчесе вазыйфасын биләде. Сугыш хәрәкәтләре ветераны.

Почет ордены, «Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале, «Җәмәгать тәртибен саклауда аерым хезмәтләр өчен», «Хезмәттәге фидакарьлек өчен», «Георгий Жуков» медальләре белән бүләкләнгән.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы җитәкчелеге һәм хезмәткәрләре Вазанов Андрей Юрьевичның гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты, әнисе

ГЫЙМАДИЕВА Нәҗия Заһит кызы

вафат булу сәбәпле, Татарстан Республикасы Президентының Эшләр идарәсе баш киңәшчесе Шәрәфетдинова Ләйсән Мәгъсүм кызының авыр кайгысын уртаклаша.

Белдерү

Кадастровым инженером Ирбулатовым Маратом Рафиковичем (почтовый адрес: 420100, г. Казань, ул. 2-Азинская, д. 1, контактный тел.: 89600488084, электронная почта marat_327@mail.ru, № квалификационного аттестата 16-15-841) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:20:070101:107, расположенного по адресу: Российская Федерация, Республика Татарстан, Зеленодольский муниципальный район, Бишнинское сельское поселение, с. Бишня, ул. Южная, д. 1, выполняются кадастровые работы по уточнению границ земельного участка.

Заказчиком кадастровых работ является Султанова Гузель Габитовна, почтовый адрес: 420059, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Коломенская, д. 3, кв. 39.

С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться в будние дни с 10:00 до 18:00 ч. по адресу: 420100, г. Казань, 2-Азинская, д. 1.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ земельного участка состоится по адресу: 420100, г. Казань, 2-Азинская, д. 1 4 мая 2022 года в 10 часов 00 минут.

Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельных участков на местности принимаются со дня опубликования в печатном издании в течение месяца по адресу: 420100, г. Казань, 2-Азинская, д. 1.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границы земельного участка: 16:20:070101:109; 16:20:070101:197; 16:20:070101:195; 16:20:070101:194; 16:20:070101 (земли общего пользования).

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.



«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ

(843) 222-09-65,
222-09-70.

E-mail: vtreklama@mail.ru

Милли көрәш

dumrt.ru

Хаҗга Шамил барачак

Келәмгә тузан кунмый. Атна ахырында республикада милли көрәш буенча берничә турнир узды. Түбән Камада батырлар Данил Галиев истәлегенә 28 нче мәртәбә оештырылган бәйгедә бил алышты. Чаллыда узган турнирда исә хаҗга юллама бүләк иттеләр.

Данил Галиев – 6 мәртәбә Муса Җәлил бәйгесе җиңүчесе, 7 тапкыр Татарстан, 8 мәртәбә Россия чемпионы. Аның истәлегенә узучы бәйге көрәш дөньясында иң мәртәбәле ярышларның берсе санала. Бу юлы әлеге турнирга 33 командадан 254 көрәшче җыелды. Алдагы атнада герой-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә газетабыз гамәлгә куйган турнирда җиңү яулаган егетләрнең дә күбесе Түбән Кама келәменә чыкты. Араларыннан бишесе әлеге ярышта да батыр булып танылды. Данил Галиев бәйгесендә җиңүче исемен Илсур Гыймадетдинов (Кукмара), Илдар Хәләфетдинов (Әлмәт), Разил Шабиев (Чистай), Динар Кәримуллин (Лаеш), Ленар Садыйков (Чаллы), Ренас Кәлимуллин (Теләче), Илмир Төхвәтуллин, Булат Мусин (икесе дә – Казанның Яңа Савин районы), Радик Сәлахов (Әлмәт), Фирдүс Зәйнуллин (Казанның Яңа Савин районы) танылдылар. Командалар беренчелеген, газетабыз турнирындагы кебек үк, Әлмәт егетләре отты.

Шимбә көнне исә Чаллыда мөселман яшьләре арасында милли көрәш һәм кул көрәше буенча берләштерелгән XIII Бөтенроссия турниры узды. Быел әлеге бәйге Идел буе Болгар дәүләтендә исламны кабул итүнең 1100 еллыгы уңаеннан оештырылды. Ярышта катнашучы өчен спортчылар намаз кылу тәртипләрен белгәннәрен дә расларга тиеш. Келәмгә шуннан соң гына чыга алалар. «Көрәш ул кыюлык, батырлык, ихтыяр көче кебек сыйфатлар тәрбияли. Намаз укучы егетләрне көрәшкә тартырга тырышабыз, алар көчле, куәтле, җитез булырга тиешләр. Чөнки мөселман кеше үзенең йортын, гаиләсен, илен саклау өчен җаваплы. Без әлеге ярыш белән ислам динендә көрәшкә һәм башка спорт төрләренә урын булуын күрсәтергә тырышабыз», – диделәр ачылу тантанасында.

Турнирның көрәш бәйгесендә 70тән артык егет бил алышты. Үз авырлыкларында җиңүче булып Рүзил Ганиев (Әлмәт), Илназ Рамазанов (Тукай районы), Марат Кәримов, Айрат Сәмигуллин, Айвар Билалов (өчесе дә Әлмәттән), Валерий Рәфыйков (Оренбург) танылдылар. Командалар арасында бу юлы да Әлмәт егетләренә тиңнәр табылмады. Кул көрәшендә исә Шамил Хәкимов, Азат Җәләев (икесе дә Түбән Камадан), Фәнис Нурхәмитов (Чаллы) җиңүче булды.

Әнә шул 9 егет арасында жирәбә уйнатып, хаҗга юллама иясе ачыкланды. Бу юлы изге сәфәргә бару Шамил Хәкимовка насыйп булды. Егеткә – 18 яшь, ул Түбән Кама политехник колледжында III курста белем ала.

«МИН – ГАГАРИН, СИН – ТАТАРИН...»

ПЛАНЕТАБЫЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ КОСМОНАВТЫ ЮРИЙ ГАГАРИН 1968 ЕЛНЫҢ 27 МАРТЫНДА ОЧКЫЧКА СЫНАУ ҮТКӘРГӘНДӘҺӘЛАК БУЛДЫ. АҢА БУ ВАКЫТТА БАРЫ ТИК 34 ЯШЬ ИДЕ

Әлбәттә инде, баш исемгә куелган сүзләр халык арасында күбрәк йөремсәк мәзәкләрдән алынган дип уйланыла. Ә бит, истәлекләрдән күренгәнчә, бу сүзләрне Гагарин үзе әйтә. Аның янәшәсендә татарлар, чыннан да, күп була һәм саллы гына урын алып тора. Шуларның берничәсе турында укучыларыбызга да сөйлик әле.

Юрий Гагарин Казанга килгәч. 1967 ел

Гариф Сәйфиев

1962 елны космоска юл яруның берьеллыгы уңаеннан Звездный шәһәрчегенә алты яңа «Волга» автомобиле кайтарыла. Бу вакытта Гагаринның шәхси йөртүчесе Татарстанның Сарман районындагы Теләнче Тамак авылы егете Гариф Сәйфиев була. Ул армия сафларында хезмәт итә. Беренче космонавт шоферы янына килә дә: «Әйдә, кайсы ошый, шунысын сайлап ал», – дип әйтә. Егетне аз сүзле, тырыш, сабыр булганы өчен хөрмәт итә ул. Гарифның өчьеллык хәрби хезмәте беренче космонавт белән янәшә үтә.

Ял көннәрендә Гагарин еш кына әнисе янына, Смоленск өлкәсендәге Гжатск шәһәренә кайта. 171 чакрым араны ике сәгать эчендә үтәләр. Беренче тапкыр кайткач, Анна Тимофеевна Гарифны өстәл янына чакыра. Егет читенсенә, кермәс өчен сәбәп эзли башлый. Космонавт шунда: «Без бит – синең белән адашлар. Мин – Гагарин, син – татарин. Мин – авыл егете, син дә – авылныкы. Оялып торма, әйдә», – дип, егетне өйгә алып керә. Хезмәте тәмамланганнан соң космонавт аңа шәһәрчектә бөтенләйгә калырга тәкъдим ясый, фатирлы итәргә вәгъдә бирә. Әмма егет, гомерен авылда үткәргән, бер сүз дә русча белмәгән өлкән яшьтәге авыру әнисенә шәһәр фатирында яшәү кыен булыр дип, баш тарта. Авылга кайткач, шофер булып эшли. Армия хезмәте турында әллә ни сөйләнеп йөрми. Бары тик 1977 елда гына гаиләсе белән Звездный шәһәренә кунакка барып кайта. Аның хатыны Долорес сәяхәт турында: «Мин СССР җитәкчеләре генә туктала торган мондый шәп кунакханәне беренче тапкыр күрдем», – дип сөйли. Гариф Сәйфиевнең истәлекләрен туганнары да, авыл халкы да кадерләп саклый.

Ядкәр Акбулатов

Бу милләттәшебез Оренбургта очучылар әзерләүче хәрби-авиация училищесының очучы-инструкторы була. 1955–1957 елларда Гагарин шушы уку йортында белем ала. Соңрак Ядкәр Шакирович беренче космонавт белән булган хәлләр турында болай дип яза:

– Гагарин белән беренче тапкыр 1955 елда очраштым. Ул көнне лагерь буенча кизү идем. Бер эскадрильяда тәртипнең аксавын күреп, старшинаны яныма чакырдым. Йокларга ятарга әмер булган иде инде. Шуңа, күрәсең, старшина майкадан, аягына итекләрен элгән килеш кенә йөгереп керде дә: «Сержант Гагарин сезнең приказ буенча килде», – дип хәбәр салды. Минем: «Сержант икәнеңне күрмим. Офицер янына ник формасыз килдең?» – дип кисәтү ясавым булды, кире йөгереп китте, 2–3 минуттан әйләнеп килеп тә җитте. Бу юлы тиешенчә, формадан иде. Мин аңа башкаларның тынычлыгын алган тәртип бозучыны табарга һәм тынычландырырга куштым.

Дәүләт имтиханнары вакытында теорияне «биш»кә генә белгән Гагарин никтер «дүртле» ала. Ядкәр Шакирович моның белән килешми. Имтиханны кабат бирүен таләп итә. Булачак космонавт бөтен биремнәрне үтәп, «бишле»гә бирә. Гагаринның космоска очуын ишеткәч, остазы башта үз колакларына ышанмый тора. Беренче космонавт Оренбургка килгәч, аны башта укучысы янына кертмиләр. Җаен табып, очрашуга генерал машинасында килә ул.

– Гагарин мине күреп алды да каршыма килә башлады. Аның тирәсендәге кешеләр як-якка китеп, юл бирделәр. Шул вакытта, чыннан да минем янга микәнни, дип уйлаганым хәтердә. Өч метр кала, нәкъ шулай икәнлегенә инандым. Үзе елмая, кулларын җәеп, кочакларга килә. Мин дә аның каршысына киттем, кочаклашып исәнләштек. «Курыкмыйча космоска менгәнең өчен рәхмәт сиңа, Гагарин (мин аны гел фамилиясе белән генә атый идем), без синең белән бик горурланабыз», – дидем. Ул җавап итеп: «Иптәш командир, үзегезгә бик зур рәхмәт! Өйрәтмәгән, укытмаган булсагыз, космоска менеп җитә алмаган булыр идем», – диде. Банкетта утырганда: «Күтәрелеп киткәндә әйтелгән «Поехали!» сүзен кайдан алдың?» – дип сорадым. «Иптәш капитан, бу бит – сезнең сүз. Теләсә нинди очыш ясаганда сез үтә дә гади итеп, ну, поехали, дип әйтә идегез. Шуны ишетүгә, бездә ышаныч туа иде. Әйтерсең, күккә менмибез, ә дилбегә тартып, атта юырттырып китәбез», – дип елмайды ул.

Әнихәят Тахтарова

Очыш тәмамлана. Космик корабль Саратов өлкәсенең Смеловка авылы янына төшә. Бу мизгел турында Гагарин үзе менә ничек яза: «Каты җиргә басуга, ала-кола бозау янында басып торучы бер хатын белән кызчыкны күреп алдым. Каршыларына киттем. Алар да миңа таба килә башладылар. Тик якынрак килгән саен, адымнарын акрынайттылар. Мин бит әле әфлисун төсендәге скафандрда идем. Күрәсең, бу ачык төс аларны бераз шүрләткәндер. Мондый әйберне күргәннәре дә булмагандыр. «Үзебезнекеләр, иптәшләр, үзебезнекеләр», – дидем мин, шлемымны салып. Бу урманчы хатыны Анна Тахтарова белән оныгы Рита булып чыкты».

«Син кайдан килеп чыктың соң?» – дигән сорауга Гагарин, корабльдән, дип җавап бирә. Корабль суда гына була бит ул, дигәч, әбекәйгә аппаратның эчен дә күрсәтеп чыга.

Чынлыкта исә рус исемнәрен Гагарин аларга үзе куша. Оныгы Румия белән Әнихәят апа була ул. Соңрак Румия Әбдерәшитовна белән булган очрашуларга багышланган язмалар да шул хакта сөйли. Миңа бу исемне Гагарин үзе кушты дип, Рита исемен дә бик ярата ул. Әбисе, әнисе Гөлчирә, әтисе Әбдерәшит исән чагында Гагарин аларга гел хатлар язып, посылкалар җибәреп тора.

Әнихәят апа, Гагарин очып төшкәндә, бакчада бәрәңге утырта торган була. Шуннан соң, һава торышы нинди булуга карамастан, бу көнне бакчага 2–3 данә булса да бәрәңге төртеп кую гаиләнең традициясенә әйләнә. Бәрәңге дигәннән, Юрий Гагарин аның бәлешен дә бик ярата торган була. Татар халкының бу тәмле ризыгы белән аны Оренбургта пешекче булып эшләүче каенатасы сыйлый.

Татарстанда Хәлил Гайнетдинов җитәкчелегендәге «Җиһангирлар» инициатив төркеме, беренче космонавтны искә алып, космос өлкәсенә битараф булмаучыларны ел саен «Гагарин бәлеше» белән сыйлый. Әлбәттә инде, бу чара мәктәпләрне, балалар бакчаларын, төрле оешмаларны үзенә җәлеп итеп, ике атнадан бик зур бәйрәмгә – Гагарин көненә әйләнә.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

veterany.tatarstan.ru

ДӘРТ БЕТМӘГӘН ӘЛЕ

Соклану

Иң өлкән кул эше остасына – 94, иң яшенә – 55 яшь. Татарстанда өлкәннәр арасында «Халык иҗаты» дигән бәйге узды. Анда 55 яшькә җиткән хатын-кызлар һәм 60 яшьтән ир-атлар катнашты. Бәйге «Ветераннар – Татарстан халыкларының мәдәни мирасын һәм үзенчәлеген саклаучылар» дигән проект кысасында тормышка ашырыла.

Өлкәннәрдән 1500 кул эше кабул ителеп алынган. Шуларның 300е республика ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасына килеп җиткән.

– Әлеге бәйгене уздыру теләге пандемия башлангач барлыкка килде. Чөнки без онлайн аралашуга күчтек. Интернетта бер төркем ачып, республика өлкәннәренең кул эшләрен күрсәтә башладык. Алар сокланып туймаслык иде. Уйлаштык та, мондый һөнәр ияләре югалмаска тиеш, дидек. Аларның эшен бәяләргә кирәк дигән нәтиҗәгә килдек, – ди республика ветераннарының (пенсионерларының) төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе Хәбир Иштирәков. – Бәйге уздырыр өчен грант оттык. Дәүләт ярдәме дә булды. Шулай итеп, җиңүчеләрне котлар өчен 700 мең сум акча җыелды. Үземә дә районнарга еш чыгарга туры килә. Кая гына барсам да, өлкәннәрнең эшләрен карап сокланып кайтам. Алар сокланмаслык түгел. Кемдер агач эшләнмәләре, берәүләр картина ясый, икенчеләре бәйли, чигүче дә, тегүче дә бар.

Журналистларга да республика өлкәннәренең эшләре белән танышырга насыйп булды. Хәбир Иштирәков белеп әйтә: өлкәннәрдә яшәү дәрте көннән-көн артып тора. Лаеклы ялга чыккач, аларның икенче сулышлары ачылган кебек.

– «Балкыш» республика фестивален генә алыйк. Аны хәзер белмәгән кеше юк инде. Башлаганда куркып кына тотынган идек. Сәхнәгә менәргә теләүчеләрнең күплеген белсәгез! Элек авыр эшләрдә эшләп, үзендә моңны, җырга сәләтне чит кешегә күрсәтмәгән алар. Араларында сыер савучылар, тракторчылар, мал караучылар, укытучылар да бар, – дип сөйли Хәбир Иштирәков. – Шушы фестиваль кысасында кул эше осталарын да күрсәтергә дип уйлыйбыз. Ул ничек буламы? Үзешчән сәнгатьтә катнашучылар районнардагы «Балкыш» фестиваленең сайлап алу турларын уздылар инде. 29 апрель көнне Казанда гала-концерт үткәрергә планлаштырабыз. Концерт башланганчы «Халык иҗаты» бәйгесендә катнашучыларның эшләреннән күргәзмә оештырмакчы булабыз.

Кул эшләренең «иң-иң»ен сайлап алу җиңел түгел. Һәр эш күңелгә якын, ди оештыручылар. Агачтан ясалган мәчет, чигелгән сөлгеләр, картиналар, ясалма гөлләр, хәтта поезд юлы да бар. Соңгысын эшләтеп тә җибәреп була.

– Өлкәннәр гореф-гадәтләрне генә түгел, халкыбызның кул эшләрен дә саклап тота. Яшьләргә өйрәтә. Алар кулына инә, балта, чүкеч, пумала тотса, ашарын-эчәрен оныта. Дөнья мәшәкатьләреннән арынып тора, – ди Хәбир Иштирәков.

Җиңүчеләрне 10 номинациядә бүләкләячәкләр. Һәр номинациядә өч урын каралган. Оештыручылар бүләкләр затлы була дип ышандыра. Бу бәйге киләчәктә дә дәвам итәчәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7101 данә
Гомуми тираж – 17132 данә

Газетага сертификат бирелде — Заказ 243

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульъязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).

16+